ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ.
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07.02.2020 — Балык Бистәсе штп. — №60пг

Муниципаль хезмәткәр тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе хакында

2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү Тәртибен расларга (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 16 маендагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленә башка түләүле эш башкару турында хәбәр итү хакында” 49пг номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Р.Җамалиевка йөкләргә.

И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башлыгының
2020 елның 7 февралендә
60пг номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү Тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә әлеге алдан хәбәр итү Тәртибе (алга таба – Тәртип) 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция китереп чыгара торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре (алга таба – муниципаль хезмәткәр) тарафыннан бүтән түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү процедурасын билгеләү максатында эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан язма рәвештә хәбәр итеп башка түләүле эшне башкарырга хокуклы, әгәр бу мәнфәгатьләр низагына китермәсә һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законда башкасы каралмаган булса.

3.Муниципаль хезмәткәр башка түләүле эшне башкарганда мәнфәгатьләр низагы барлыкка килгән очракта башка түләүле эшне башкаруны туктатырга тиеш.

4. Башка түләүле эшне башкарырга планлаштыручы муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә башка түләүле эшне башкару турында муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе белән алдан килешенеп әлеге Тәртипкә бирелгән 1 нче кушымта нигезендә язма рәвештә хәбәр итә (алга таба – хәбәрнамә). Күрсәтелгән хәбәрнамә башка түләүле эшне башкара башлаганчы җибәрелергә тиеш.

5. Хәбәрнамә кергән көнне әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта рәвеше буенча алып барыла торган башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү журналына теркәлергә тиеш.

6. Хәбәрнамә хәбәр килеп ирешкән көннән алып өч эш көне эчендә яллаучы вәкиленә (эш бирүче) вәкиленә тапшырыла.

7. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эш башкаруына каршы чыкса, хәбәрнамә бланкында ул муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эше мәнфәгатьләр низагына китерергә мөмкин булуы турында үз фикерен нигезли.

8. Яллаучы (эш бирүче) вәкилендә муниципаль хезмәткәрнен мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеге турында шик барлыкка килгән очракта муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамәсе муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмә нигезендә өч көн эчендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссиягә карауга җибәрелә.

9. Башка түләүле эшне башкару графигы, шулай ук мондый эшне башкару белән бәйле башка йөкләмәләр үзгәргән очракта, муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә әлеге Тәртип нигезендә хәбәр итә.

______________________________

*(танышу турында тамга)*

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү Тәртибенә КУШЫМТА №1

______________________________________________
*(яллаучы (эш бирүче) вәкиленең Ф.И.А.и.)*

______________________________-дан (-тан)
*(муниципаль хезмәткәр вазифасын биләүченең Ф.И.А.и.)*

**башка түләүле эш башкару турында**
**ХӘБӘРНАМӘ.**

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсенең 2 өлеше нигезендә мин 20____елның "___"________________-нан(-нән) башлап ______________________________________________________________________буенча
*(хезмәт шартнамәсе, гражданлык-хокукый шартнамә, авторлык шартнамәсе һ.б.ш.)*
______________________________________________________________________-да(-та)
*(бүтән түләүле эш гамәлгә ашырыла торган оешманың тулы исеме(атамасы), әлеге оешманың адресы)*
түләүле эшчәнлек:____________________________________________________________
*(эшчәнлек төрен күрсәтергә: педагогик, фәнни, иҗади яки башка)*
башкарырга ниятлим.
________________________________________________________________буенча эш
*(башкарылачак эшнең характерын күрсәтергә: мәсәлән, "студентларны укыту буенча", "мәкаләләр язу буенча" һ.б.)*
мәнфәгатьләр низагы барлыкка килүгә китермәячәк.
20___елның "___"___________ ______________________

______________________________ ______________________________
*(хәбәрнамәне юллаучы затның имзасы)* *(имзаның расшифровкасы)*

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

_______________________________ _______________________________

*(хәбәрнамәне килештерүче вазифаи затның вазифасы, Ф.И.А.и.)* *(имза, дата)*

Башка түләүле эшне башкару турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналында теркәү номеры №______

Хәбәрнамәне теркәү датасы: 20___елның “___”____________ .

_____________________________________ _____________________________________

*(хәбәрнамәне теркәгән вазифаи затның Ф.И.А.и.)* *(хәбәрнамәне теркәгән вазифаи затның имзасы)*

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы хезмәткәре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү Тәртибенә КУШЫМТА №2

## Башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Хәбәрнамәне тәкъдим иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и. | Хәбәрнамәне тәкъдим иткән муниципаль хезмәткәрнең вазифасы | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге (эшчәнлекнең характеры), башка түләүле эш гамәлгә ашырылачак оешманың исеме (атамасы) | Хәбәрнамәне кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и., имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |